**ГЛАВА ЧЕПЧУГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Чепчуги, ул.Советская, 10Б

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫПЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур, 10Б

Тел./факс: +7(84365) 72-5-01 e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**17 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Иске Бөреле, Яна Бөреле торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21 октябрендәге 131 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары (Советның 12.05.2020 №152, карарлары редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2021 елның 28 ноябрендә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Иске Бөреле торак пунктында;

1.2. 2021 елның 28 ноябрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Яна Бөреле торак пунктында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Иске Бөреле торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Иске Бөреле торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

1) вак таш сатып алу һәм Иске Бөреле торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга

2) чокырны ныгыту

3) урам спорт инвентаре сатып алу

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Яна Бөреле торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Толмач торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

1) Яна Бөреле торак пунктында урамны яктыртуы

2) Яна Бөреле торак пунктында Яшел урам һәм Малмыж-Казан юлы киселешендәге яңгыр сулары торбасын урнаштыру

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чыпчык авыл җирлеге башлыгы И.Р.Җиһаншин